СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
**26.04.2019**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 384**

Зеленодольск муниципаль районы Советының 2016 елның 28 октябрендәге “Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзи торган оешмаларга, шулай ук әлеге исемлеккә кертелгән мөлкәтне арендага һәм (яисә) озак вакытлы файдалануга бирү (шул исәптән ташламалы аренда түләве ставкалары буенча) тәртибе һәм шартлары турында, өченче затлар хокукларыннан (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) азат ителгән муниципаль милек исемлеген формалаштыру, алып бару, мәҗбүри бастырып чыгару тәртибе турында” 140нчы карары кушымтасына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

2018 елның 3 июлендәге «Кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәт хокукларын арттыру максатыннан Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 185-ФЗ Федераль законының 3нче маддәсендәге 3нче пунктының а, б, в, г пунктчалары нигезендә, 2007 елның 24 июлендәге «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлык үсеше турында» 209-ФЗ Федераль закон белән, Зеленодольск муниципаль районы **карар итте:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Советының 2016 елның 28 октябрендәге 140 номерлы карары белән расланган кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга озак сроклы нигездә (шул исәптән аренда түләвенең ташламалы ставкалары буенча) файдалануга

бирү өчен билгеләнгән өченче затлар хокукларыннан азат ителгән муниципаль мөлкәт исемлеген (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш)  формалаштыру, алып бару, мәҗбүри бастырып чыгару тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 1.5нче  пунктта. «шул исәптән җир кишәрлекләре» сүзләреннән соң «(шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык, шәхси торак төзелеше өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән тыш) " сүзләрен өстәргә.

1.2. 1.8нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.8. 2008 елның 22 июлендәге “Дәүләт яисә муниципаль мөлкәттә булган һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендаланган күчмәс мөлкәтне  тартып алу үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 159-ФЗ Федераль закон нигезендә һәм Россия Федерациясе  Җир кодексының 39,3нче маддәсенең 2нче пунктындагы 6нчы, 8нче һәм 9нчы пунктчаларында күрсәтелгән очракларда кече һәм урта эшкуарлык мөлкәтен бушлай тартып алудан тыш Субъектлар өчен исемлеккә кертелгән муниципаль мөлкәтне сату тыела. Күрсәтелгән мөлкәтне шулай ук алардан куллану хокукын бирү, файдалану хокукын залогка бирү һәм хуҗалык эшчәнлегенең башка субъектлары  устав капиталына шундый мөлкәттән файдалану хокукын кертү, шундый мөлкәт аренда килешүләре буенча  хокук һәм бурычларны өченче затларга күчерү, шундый мөлкәтне кече һәм урта эшкуарлык субъектлары инфраструктурасын төзегән кече һәм урта эшмәкәрлек оешмалары субъектларына, әгәр дә 2006 елның 26 июлендәге “Конкуренцияне яклау турында” 135-ФЗ Федераль законның 17.1нче маддәсенең 1нче өлешендәге 14нче пунктында каралган мөлкәт субарендага бирелгән очракта субарендага бирү тыела.

2. Зеленодольск муниципаль районы Советының 2016 елның 28 октябрендәге 140нчы карары белән расланган кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга озак сроклы нигездә (шул исәптән аренда түләвенең ташламалы ставкалары буенча) файдалануга бирү өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәт исемлегенә кертелгән муниципаль милекне арендага бирү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

2.1. 2.8нче пунктта «бер өлеше 2.1. Федераль законның 9нчы маддәсенең 2.1нче өлеше белән” сүзләрен «Федераль закон белән" сүзләренә алмаштырырга;

2.2. 2.8нче пунктында «Россия Федерациясе актлары» сүзләреннән соң «Россия Федерациясе Җир кодексының 39.3нче маддәсенең 2нче пунктындагы 6нчы, 8нче һәм 9нчы пунктчаларда күрсәтелгән очракларда» сүзләрен өстәргә.

3.Әлеге карарны «Зеленодольская правда» газетасында бастырып чыгарырга һәм шулай ук әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр порталы составында Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

Зеленодольск муниципаль
районы башлыгы,
Совет рәисе А.В.Тыгин